УДК 811.512.145

***А.И. Идиятуллина,***
***А.Я. Хөсәинова***

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ МЕТЕОРОЛОГИК ЛЕКСИКАСЫН ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫ

Изучение метеорологических названий в татарском языке представляет собой важное направление лексикологических исследований, позволяющее проследить не только историю развития языка, но и особенности взаимодействия человека с окружающей средой, отраженные в языковой картине мира. Метеонимы, будучи неотъемлемой частью повседневной жизни народа, аккумулируют в себе богатый пласт знаний о природных явлениях, связанных с климатическими условиями региона и традиционными формами хозяйственной деятельности. Несмотря на значимость данной лексической группы, история ее изучения в татарском языкознании до сих пор не получила должного освещения. Настоящая статья ставит своей целью проследить основные исследования метеорологических названий в татарском языке. В статье рассмотрены труды ученых, внесших вклад в изучение данной проблематики, проанализированы методы и подходы к анализу метеорологической лексики, а также обозначены перспективные направления дальнейших исследований.

**Ключевые слова**: метеорологическая лексика, диалектология, диалектная лексика, метеонимы, татарский язык.

The study of meteorological names in the Tatar language is an important area of lexicological research, which allows us to trace not only the history of language development, but also the features of human interaction with the environment, reflected in the linguistic picture of the world. Meteorological terms being an integral part of the daily life of the people accumulate a rich layer of knowledge about natural phenomena related to the climatic conditions of the region and traditional forms of economic activity. Despite the importance of this lexical group the history of its study in Tatar linguistics has not yet received adequate coverage. This article aims to trace the main stages of the study of meteorological names in the Tatar language, starting with the first lexicographic works and ending with modern research in the field of dialectology, semantics and ethnolinguistics. The article will review the key works of scientists who have contributed to the study of this issue, analyze methods and approaches to the analysis of meteorological vocabulary and identify promising areas for further research.

**Keywords:** meteorological vocabulary, dialectology, dialect vocabulary, meteorological names, tatar language.

Кешенең дөньяга карашында климат һәм һава торышы күренешләре аерым урын алып тора, аның тормышына һәм үз-үзен тотышына зур йогынты ясый. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү һәм танып белү процессында кеше һава торышы күренешләрен өйрәнергә генә түгел, ә аларны тасвирларга һәм бәяләргә дә тырышкан. Бу белемнәрнең барысы да телдә махсус берәмлекләр – метеонимнар

ярдәмендә чагылыш таба. Лингвистикада һава торышы өлкәсенә караган лексиканы метеоним, яисә метеорологик лексика дип атыйлар.

Метеорологик лексика дөнья телләрендәге киң үсеш алган тематик төркемнәрнең берсен тәшкил итә. Бу хәл тормыш-көнкүрештә һава торышының әһәмиятле роль уйнавы белән бәйле. Әлеге мәкаләнең максаты – татар телендәге метеорологик лексика мәсьәләләренә бәйле булган публикацияләргә күзәтү ясау, анализлау, шулай ук алга таба тикшеренүләрнең перспектив юнәлешләрен билгеләү.

Эшнең фәнни һәм гамәли әһәмияте фәнни басмаларның төрле критерийлар буенча классификациясе, аларның эчтәлеген анализлау һәм өйрәнелә торган проблематика буенча төп фәнни хезмәтләргә күзәтү ясау белән билгеләнә.

Татар телендәге метеонимнарны өйрәнү тарихын төрки тел белеме яссылыгында карау зарури санала. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: әлеге тематик төркем тюркологиядә тиешле дәрәҗәдә тикшерелмәгән, метеонимнарны монографик планда өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләр күп түгел. Мәсәлән, казах, кыргыз, азәрбайҗан һәм башкорт телләренә караган диссертацияләр (Н. Базылхан, 1998; В.Б. Джафаров, 1990; А.Г. Искандаров, 2009; К. Сагындыкова, 2012) яктыланган, башка төрки телләрдә аерым мәкаләләр (Р.З. Хафизова, 2015; Р.Р. Җамалетдинов, 2020; М.З. Улаков, 2021; Н.И. Данилова, 2019 һ. б.) бар. Шул ук вакытта алар арасында метеорологик лексиканы комплекслы рәвештә колачлаган хезмәтләр бик аз (Л.В. Данилова. «Метеорологическая лексика тюркских языков»; В.Б. Джафаров. «Метрологические термины в азербайджанском языке»; А.Г. Искандаров. «Метеорологическая лексика башкирского языка»; К.С. Сагындыкова. «Кыргыз тилинде жаратылыш кубулуштарынын атоолору» («Кыргыз телендә табигать күренешләренең атамалары»)). Шулай ук метеорологик лексика проблематикасының аерым аспектларына багышланган хезмәтләр дә бар [6: 234].

Аерым өлкәгә караган лексиканы системалы рәвештә тикшерү хәзерге татар тел белеменең мөһим юнәлешләреннән берсе булып тора. Аш-су, кием-салым, кош-корт, үсемлек атамаларына багышланган фәнни хезмәтләр күп булуга карамастан, метеорологик лексиканы өйрәнүгә караганнары азсанлы.

Алга таба тәкъдим ителгән тикшеренүләрне лингвистика юнәлешләре буенча классификацияләп карыйбыз.

Күпчелек хезмәтләр чагыштырма планда башкарылган, һәм аларда тугандаш телләр дә, тугандаш булмаган телләр дә тикшерелә. Мәсәлән, В.С. Дмитриева һәм Г.И. Илдархhandованың «Лексика природных явлений в русском, татарском и турецком языках» (1998) китабында тикшерену объекты – рус, татар һәм төрек телләрендә табигать күренешләрен атаучы исемнәрнең тематик төркеме. Авторлар метеонимнарны анализлап, әлеге тематик бүленеш эчендә 6 лексик-семантик төркем аерып чыгаралар: атмосфера явым-төшемнәре, һава массаларының хәрәкәте, гомуми күренешләр, атмосфераны тоныкл-

ландыра торган матдәләр, атмосфераның температура халәтләре, яктылык күренешләре. Хезмәттә төп метод буларак чагыштырма-типологик метод кулланыла [2: 6].

Ә.М. Галиева һәм Р.Р. Җамалетдиновларның «Семантика и сочетаемость татарских глаголов, обозначающих природные явления» (2017) хезмәтендә табигать күренешләрен туры мәгънәдә белдергән татарча синтетик фигыльләр карала. Төп игътибар һава торышы белән бәйле субстантив фигыльләргә бирелә. Бу төркемнең үзәген һава торышы белән бәйле күренешләрне белдерүче фигыльләр тәшкил итә: явым-төшемнәр, температура үзгәрү, болытлы көн, җил көче һ. б. Мәсәлән, яву (падать – об осадках), исү (дуть – о ветре), күкрәү (грохотать – о громе), буранлау (вьюжить), давыллау (бушевать – о буре) [1: 18].

Татар телендә метеонимнар чагыштырма аспектта тикшерелгән тагын бер хезмәтне билгеләп үтәргә кирәк. Д.Д. Хәйруллина, Э.Н. Гыйләҗева, Л.В. Базароваларның «Особенности номинации природного явления «дождь» в английском и татарском языках» (2021) мәкаләсендә инглиз һәм татар телләрендә «яңгыр» күренешен аңлаткан лексемаларының семантик һәм функциональ үзенчәлекләре ачыклана. Эшнең фәнни яңалыгы шунда: әлеге лексик катлам беренче тапкыр типологик һәм генетик яктан кардәш булмаган телләрдә, чагыштырма аспектта өйрәнелә. Нәтиҗәдә, инглиз телендә яңгыр номинацияләренең ачыграк тасвирланганлыгы дәлилләнә. Инглиз теленнән аермалы буларак, татар телендә кайбер метеонимнарның уңай мәгънәгә ия булуы ачыклана. Моны төбәкнең географик үзенчәлекләре һәм климат шартлары белән аңлатырга мөмкин дип фаразлана [10: 918].

Соңгы дистә елларда лингвистикада когнитив һәм лингвокультурологик тикшеренүләргә игътибар арта бара. Метеолексика буенча хезмәтләр дә әлеге тенденциягә иярә. Мәсәлән, күренекле филолог, профессор А.Г. Шәйхулловның «Структура и идеографическая парадигматика односложных корневых основ в кыпчакских языках Урало-Поволжья в континууме ареальной, межтюркской и общетюркской лексики (синопсис и таксономия когнитивной сферы)» (2000) монографиясендә татар һәм башкорт телләрендә ареаль, гомумтөрки апеллятив лексика җирлегендә терек булмаган табигать дөньясы белән бәйле (Җир. Җир киңлеге. Су. Су киңлеге. Космос. Космос киңлеге. Һава. Һава киңлеге. Климат. Һава торышы) бер иҗекле тамырлар классификациясе һәм аларны төркемләү принциплары тикшерелә.

Берничә хезмәт метерологик лексиканы этнолингвистика юнәлешендә – халык метеорологиясе, ырымнар һәм ышанулар аша өйрәнүгә багышланган. Филология фәннәре кандидаты М.И. Закировның татар теленең метеорологик лексикасына бәйле берничә мәкаләсе бар. Аларда автор метеонимнарның татар халык авыз иҗаты әсәрләрендә, халык ышануларында, шулай ук фразеологик системада да чагылышын тикшерә. Мәсәлән, «Лексема дождь в русских и татарских

народных приметах» (2008) хезмәтендә рус һәм татар халык сынамышларында яңгыр лексемасы чагыштырма планда карала. Халык сынамышларын өйрәнүнең культурологик нигезләре тикшерелә, чагыштырыла торган телләрдә яңгыр сүзенең мәгънә вариантлары күрсәтелә, рус һәм татар халык сынамышларына тәфсилле характеристика бирелә. Яңгыр лексемасы кергән халык сынамышлары «атмосфера явым-төшемнәре» лексик-семантик төркеме мисалында тәкъдим ителә [4: 144].

Шул ук авторның «Лексема снег в русских и татарских народных приметах» (2008) дигән мәкаләсендә халык сынамышларында кар лексемасы чагыштырма аспектта карала. Хезмәттә халык сынамышларын өйрәнүнең культурологик нигезләре билгеләнә, чагыштырыла торган телләрдә кар сүзенең мәгънәләре китерелә, өйрәнелә торган лексема кергән сынамышлар тикшерелә.

М.И. Закировның «Сопоставительная характеристика лексем вода и су в народных приметах русского и татарского языков» (2008) мәкаләсе рус һәм татар телләрендә вода һәм су лексемаларын чагыштыруга багышлана, әлеге сүзләргә культурологик аспекттан чыгып анализ бирелә, шулай ук аларның лексик яктан туры килү-килмәве ачыклана.

Р.З. Хафизованың «Лексема дождь (яңгыр) в татарском языке» (2015) мәкаләсендә татар әдәби телендә һәм аның диалектларында яңгыр төрләрен билгеләү өчен күп кенә атамаларда чагылган яңгыр образын кабул итү анализлана. Мәсәлән, «ләйсән яңгыр», «койма яңгыр», «пыскак яңгыр», «җилле яңгыр» кебек татар теленә генә хас үзенчәлекле лексик берәмлекләр ачыклана [11: 202]. Шулай ук яңгыр белән бәйле гореф-гадәтләргә, мәкальләргә һәм халык сынамышларына бәяләмә бирелә (мәсәлән, «яңгыр боткасы» йоласы).

Татар теленең диалектларында метеонимнарны өйрәнү беркадәр Т.Х. Хәйретдинова мәкаләләрендә («Салават күперен кем ничек атый?» (2000), «Татар сөйләшләрендә табигать күренешләре белән бәйле кайбер сүзләр» (2002), «“Аҗаган” төшенчәсенең татар сөйләшләрендә бирелеше» (2002)) чагылыш таба. Әлеге хезмәтләрдә диалектларда теркәлгән метеорологик аппеллятивларның семантик структурасына идеографик һәм ономасиологик анализ позицияләреннән тасвирлама бирелә. Метеонимнарның семантик үзенчәлекләре анализлана, формалашу чыганаклары һәм юллары тикшерелә һәм шул нигездә татар сөйләшләре вәкилләренең һава торышы процессларына үзенчәлекле карашы турында нәтиҗәләр ясала. Мәсәлән, аҗаган сүзенең сөйләшләрдә таралыш үзенчәлекләре изоглоссалар ярдәмендә тикшерелә: 1) әҗәгай/нажакай – Урал төбәге сөйләшләре; 2) йәшен сүзе белән сүзтезмәләр – көнбатыш диалект сөйләшләре; 3) арыш камчалау – казан арты сөйләшләре өчен характерлы [9: 122].

Шулай итеп, метеонимнар телнең сүзлек составының мөһим өлешен тәшкил итә. Шул ук вакытта әлеге лексик төркем, башка лексик-

семантик төркемнәр белән чагыштырганда, татар телендә аз өйрәнелгән.

Татар телендәге метеорологик лексикага багышланган публикацияләрне анализлау күрсәткәнчә, эшләрнең күбесе чагыштырма планда башкарыла, әлеге хезмәтләрдә метеонимнар төрле аспектларда өйрәнелә. Күрсәтелгән тикшеренүләрдә метеонимнар хәзерге тел материалында анализлана, ягъни синхрон аспектта тикшерелә.

Безнең фикеребезчә, гомумхалык телендә метеонимнарны өйрәнү аеруча әһәмиятле, чөнки ул әдәби телнең төгәллеген чагылдыра һәм диалекталь тел байлыгын үз эченә ала.

Татар диалектларында метеорологик күренеш атамаларын җыю, системалаштыру һәм анализлау – киләчәктәге тикшеренүләрнең мөһим бурычы. Бу – татар теленең лексик байлыгын тулырак ачарга, диалектларның үзенчәлекләрен ачыкларга һәм гомумән, татар халкының мәдәни мирасын сакларга ярдәм итәчәк.

Әлеге өлкәдә алга таба тикшеренүләрнең түбәндәге перспектив юнәлешләрен билгеләргә мөмкин. Системалаштыру ягыннан татар диалектларындагы барлык метеонимнарны җыеп, тасвирлап, соңыннан диалекталь сүзлекләр һәм глоссарийлар төзү зарур. Ареалогик яссылыкта метеонимнарның географик таралышын өйрәнү, изоглоссларны билгеләү татар теленең диалекталь бүленешен һәм тарихи үсешен ачыкларга ярдәм итәчәк. Тарихи аспектта сүзләрнең килеп чыгышын, аларның борынгы төрки мирас белән мөнәсәбәтләрен, шулай ук гарәп-фарсы, рус һәм фин-угор алынмаларының йогынтысын анализлау тел тарихын тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә. Чагыштырма метод ярдәмендә диалекталь метеонимнарны татар әдәби теле, башка кардәш һәм күрше телләрдәгеләре белән чагыштырып, аларның уртак үзлекләрен һәм үзенчәлекләрен күрсәтеп була.

Әлеге тикшеренүләр татар диалектларының байлыгын ачу белән беррәттән, халык тормышының әйләнә-тирә мохит белән аерылгысыз бәйләнешен, мәдәни-тарихи мирасны, шул исәптән халык метеорологиясенең бай традицияләрен тирәнтен өйрәнергә булышыр.

**Әдәбият**

1. *Галиева А.М., Замалетдинов Р.Р.* Семантика и сочетаемость татарских глаголов, обозначающих природные явления // Филология и культура. Philology and Culture. 2017. № 3 (49). С. 17–25.

2. *Дмитриева В.С., Ильдарханова Г.И.* Лексика природных явлений в русском, татарском и турецком языках // науч. ред. Ф.А. Ганиев. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1998. 105 с.

3. *Закиров М.И.* Лексема дождь в русских и татарских народных приметах // Вестник Чувашского университета. Гуманитарные науки. 2008. № 3. С. 140–145.

4. *Закиров М.И.* Лексема снег в русских и татарских народных приметах // Вестник Вятского государственного университета. Лингвистика. 2008.

5. *Закиров М.И.* Сопоставительная характеристика лексем вода и су в народных приметах русского и татарского языков // Вестник ТГГПУ. 2008. № 3 (14).

6. *Милованова Н.В.* Исследования метеолексики в современной лингвистике: к степени изученности вопроса // Известия КазУМОиМЯ им. Абылай хана. Серия «Филологические науки» 2025. № 1 (76). С. 230–243.

7. *Хәйретдинова Т.Х.* Салават күперен кем ничек атый // Материалы Итоговой науч.-практ. конф. за 1999 г. Казань: Изд-во Татар. гос. гуманит. ин-та, 2000. С. 41–43.

8. *Хәйретдинова Т.Х.* Татар сөйләшләрендә табигать күренешләре белән бәйле кайбер сүзләр // Актуальные проблемы тюркской и финно-угорской филологии: теория и опыт изучения. Материалы Всерос. науч.-практ. конф. (10–12 декабря 2002 г., г. Елабуга). Елабуга, 2002. С. 192–197.

9. *Хәйретдинова Т.Х.* «Аҗаган» төшенчәсенең татар сөйләшләрендә бирелеше // Актуальные вопросы татарского языкознания. Казань: Фикер, 2002. С. 117–122.

10. *Хайруллина Д.Д., Гилязева Э.Н., Базарова Л.В.* Особенности номинации природного явления «дождь» в английском и татарском языках // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2021. Т. 14. Вып. 3. С. 918–922.

11. *Хафизова Р.З.* Лексема дождь (яңгыр) в татарском языке // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2015. № 8 (50). С. 201–204.

12. *Шайхуллов А.Г.* Структура и идеографическая парадигматика односложных корневых основ в кыпчакских языках Урало-Поволжья в континууме ареальной, межтюркской и общетюркской лексики (синопсис и таксономия когнитивной сферы // Природа (живая и неживая). Уфа, 2000. С. 327–360.

***Идиятуллина Алия Илдус кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге кече фәнни хезмәткәре*

***Хөсәинова Алинә Җәмил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Идиятуллина Алия Ильдусовна,***
*младший научный сотрудник отдела общей лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*aliya1311@mail.ru*

***Хусаинова Алина Ямиловна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела ареальной лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*husainova_alina@mail.ru*